СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**30.05.2018**

**КАРАР**
**№ 306**

Зеленодольск
шәһәре

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 1 февралендәге 36 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 24 мартындагы 58 номерлы , 2007 елның 9 июлендәге 195 номерлы, 2008 елның 29 апрелендәге 295 номерлы, 2010 елның 26 февралендәге 508 номерлы, 2010 елның 20 декабрендәге 25 номерлы, 2012 елның 20 апрелендәге 149 номерлы, 2012 елның 2 июлендәге 156 номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 362 номерлы, 2015 елның 22 маендагы 531 номерлы, 2015 елның 20 августындагы 560 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясе рәисе Г.Т. Савельев мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 1 февралендәге 36 номерлы карары (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 24 мартындагы 58 номерлы , 2007 елның 9 июлендәге 195 номерлы, 2008 елның 29 апрелендәге 295 номерлы, 2010 елның 26 февралендәге 508 номерлы, 2010 елның 20 декабрендәге 25 номерлы, 2012 елның 20 апрелендәге 149 номерлы, 2012 елның 2 июлендәге 156 номерлы,

2014 елның 21 февралендәге 362 номерлы, 2015 елның 22 маендагы 531 номерлы, 2015 елның 20 августындагы 560 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламентына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1)51 статьяда:

1.1) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Район Советы муниципаль норматив хокукый актларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм Район Уставында билгеләнгән компетенциясе чикләрендә, татар һәм рус телләрендә кабул итә. Муниципаль норматив булмаган хокукый актлар, гаризалар, мөрәҗәгатьләр, декларацияләр Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә кабул ителә.»;

2)53 татьяда:

2.1) пунктта икенче абзацны өченче абзац дип санарга;

2.2) пунктны түбәндәге эчтәлекле икенче абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль норматив хокукый актлар проектлары татар һәм рус телләрендә кертелә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск**
**муниципаль районы**
**Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**